Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

# КАРАР № XIII-1

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 30 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Советының 2015 елның 25 июнендәге Х-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Анатыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш эшләрен җайга салу тәртибен камилләштерү максатларында, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексының 8 маддәсендәге 1 өлешенә, 32, 33 маддәләренә, Россия Федерациясе Җир кодексына, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, Анатыш авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык (гавами) тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2021 елның 23 августындагы 1 нче номерлы бәяләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Советының 2015 елның 25 июнендәге Х-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Анатыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр), Кагыйдәләрнең 30 маддәсенең 1.2 пунктын яңа редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

“1.2. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның иң чик параметрлары:

**Кишәрлекнең үлчәмнәре:**

Җир кишәрлекләренең билгеләнгән үлчәмнәре:

Кишәрлекнең минималь үлчәме - 1000 кв.м

Кишәрлекнең максималь үлчәме - 5000 кв.м

**Төзелмәләрнең биеклеге:**

Төп төзелмә катларының иң чик саны - 3 кат (мансард катын да кертеп);

Төп төзелмәнең иң чик биеклеге – 10 м;

Ярдәмче төзелмәләр катларының иң чик саны – 1;

Ярдәмчел төзелмәләрнең иң чик биеклеге - 3,5 м (яссы түбәле), 4,5 м (скат түбәле, конекка чаклы биеклек).

Киртәләрнең максималь биеклеге – 2,0 м.

**Төзелеш коэффициенты:**

Утар тибындагы төзелеш коэффициенты – 0,2

Блокланган йортлар төзү коэффициенты – 0,3

**Күрше кишәрлекләрдә урамнардан һәм төзелмәләрдән минималь ераклыклар:** урамнарның кызыл линиясеннән алып торак йортка кадәр - 5 м, килү юлларының кызыл линиясеннән алып торак йортка кадәр - 3 м;

күрше кишәрлек чикләреннән алып торак йортка кадәр – 3 м;

торак бина тәрәзәләреннән алып күрше кишәрлектә урнашкан хуҗалык корылмаларына кадәр - кимендә 10 м;

кишәрлек чигеннән алып хуҗалык корылмаларына кадәр – 1 м;

бәдрәфтән күрше йортның диварына кадәр (үзәкләштерелгән канализация булмаганда) – кимендә 12 м;

бәдрәфтән (үзәкләштерелгән канализация булмаганда) су белән тәэмин итү чыганагына кадәр – кимендә 25 м;"

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Советының 2015 елның 25 июнендәге X-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Анатыш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренең кушымтадагы редакциядә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге территориясеннән файдалануның шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына һәм махсус шартлары булган картасына кадастр номеры 16:34:0101:346, мәйданы 4 096 кв.м булган, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Анатыш авылы, Клуб ур., 54 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген үз эченә алган территориягә карата транспорт инфраструктурасы зонасын билгеләү өлешендә (И1) үзгәрешләр кертергә һәм расларга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Анатыш авылы, Клуб урамы, 17 йорт; Набережная урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов